ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 572-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 572-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 11 июле
№ 2578-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелә

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш),
№ 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 86 (I өлеш), № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 32 статьяга түбәндәге эчтәлектәге 8 пунктны өстәргә:

«8. Дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган, аларда ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга (алга таба – ятим балалар) милек хокукында туры килүче, «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә гарантияләр турында» 1996 елның 21 декабрендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясында каралган, ятим балаларны торак урыннар белән тәэмин итү хокукын гамәлгә ашыру тәртибендә бирелгән торак йортлар яки блоклы төзелештәге йортлар урнашкан җир кишәрлекләре ятим балаларга милеккә бушлай бирелә.»;

2) түбәндәге эчтәлектәге $32^2$ статьяны өстәргә:

«$32^2$ статья. **Ятим балаларга җир кишәрлекләрен милеккә бушлай бирү тәртибе**

1. Әлеге Кодексның 32 статьясының 8 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү мондый җир участогы белән идарә итү хокукына ия булган башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы яки җирле үзидарәнең вәкаләтле органы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Бирелгән җир кишәрлегенең мәйданы мондый җир кишәрлегенең мәйданы турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрындагы мәгълүматларга ярашлы рәвештә билгеләнә.

3. Җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү яки җир кишәрлеген бирүдән баш тарту турында карар Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{14}$ – $39^{17}$ статьяларына ярашлы рәвештә башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы яки җирле үзидарәнең вәкаләтле органнары тарафыннан кабул ителә.

4. Башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы яки җирле үзидарәнең вәкаләтле органы ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек аша Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{14}$ статьясында каралган тәртиптә гариза биргән гражданның (алга таба – гариза бирүче) җир кишәрлеген бирү хокукын раслаучы түбәндәге документларны сорый:

1) сорала торган җир кишәрлегенә Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;

2) сорала торган җир кишәрлегендә урнашкан торак йортка яки блоклы төзелештәге йортка Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;

3) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы вәкаләтле органының гариза бирүчегә торак йорт яки блоклы төзелештәге йортны махсуслаштырылган торак бинаны арендалау килешүе буенча «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә гарантияләр турында» 1996 елның 21 декабрендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясында каралган хокукны гамәлгә ашыру тәртибендә бирү турында карары;

4) әлеге пунктның 3 пунктчасында күрсәтелгән торак йортны яки блоклы төзелештәге йортны гариза бирүче милкенә тапшыру турында килешү.

5. Әлеге статьяның 4 пунктында күрсәтелгән документлар гариза бирүче тарафыннан үз инициативасы буенча тапшырыла ала.

6. Әгәр торак йорт яки блоклы төзелештәге йорт гариза бирүче, аның ире (хатыны) һәм (яки) балаларының гомуми өлешле милкендә булса, җир участогы аларга торак йортка яки блоклы төзелештәге йортка милек хокукындагы өлешкә пропорциональ рәвештә гомуми өлешле милеккә бушлай бирелә.

7. Әлеге статьяның 6 пунктында күрсәтелгән очракта, башкарма хакимиятнең вәкаләтле органына яки җирле үзидарәнең вәкаләтле органына өстәмә рәвештә тапшырыла:

1) өлешле милекнең һәр катнашучысыннан җир кишәрлеген бирү турында гариза;

2) өлешле милектә һәр катнашучының шәхесен раслаучы документлар;

3) өлешле милектә катнашучы вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ (вәкил мөрәҗәгать иткән очракта).».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**

# АҢЛАТМА

Бүгенге көндә Татарстан Республикасында күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләре бирүгә бәйле мәсьәләләр күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләре бирү вариантларын киңәйтү кирәклеген таләп итә.

Беренче этапта җир кишәрлекләре дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге буш җирләрдән бирелде. Шулай ук федераль милектәге җир кишәрлекләре дә бирелде.

Муниципаль берәмлекләр тарафыннан тапшырылган мәгълүмат нигезендә җир кишәрлекләре белән тәэмин ителмәгән күпбалалы гаиләләрнең иң күп саны шәһәр округларында ачыкланды. Хәзерге вакытта шәһәр округларында әлеге категориядәге гражданнарга бирү өчен җир кишәрлекләре җитмәү проблемасы бар. Проблеманы хәл итү варианты буларак күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлеген башка муниципаль берәмлектән алу хокукын билгеләү тора.

Закон проектында Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^1$ статьясына үзгәреш кертү тәкъдим ителә, аның нигезендә шәһәр округы территориясендә даими яши торган күпбалалы гаиләләргә тиешле шәһәр округы милкендәге һәм республиканың башка муниципаль районнары чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре бирелергә мөмкин. Аерым алганда, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә даими яши торганнарга җир кишәрлекләре Югары Ослан, Биектау, Зеленодольск, Лаеш, Питрәч муниципаль районнары чикләрендә, «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә даими яши торган гражданнарга – Тукай муниципаль районы чикләрендә бирелергә мөмкин.

Закон проекты белән җир кишәрлекләре бирү максатларында Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары арасындагы хезмәттәшлек тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә дип күздә тотыла.

Моннан тыш, закон проектында, «Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 2024 елның 23 гыйнварындагы 63 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указының 2 пункты нормасын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм $32^1$ статьяларына үзгәрешләр кертелә: өлкән балага 18 яшь тулганчы яисә 23 яшь тулганчы, ул белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге уку рәвешендә белем алган очракта, күпбалалы гаиләнең җир кишәрлеге алу турында гариза бирү хокукы карала.

**«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тану, туктатып тору, аларга үзгәрешләр кертү яисә аларны кабул итү таләп ителми.

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итү өч һәм аннан күбрәк баласы булган шәһәр округы территориясендә даими яши торган гражданнарга идарә итү һәм эш йөртү Татарстан Республикасы гамәлгә ашыра торган җир кишәрлекләре бирелгәндә җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары арасындагы хезмәттәшлек тәртибен раслау турында» 2016 елның 30 сентябрендәге 696 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертүне таләп итәчәк.

**«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында»**
**Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү җир кишәрлекләре алу хокукы булган күпбалалы гаиләләр санын артыруга китерергә мөмкин.

Әлеге сан зур булмас дип көтелә, чөнки күпчелек күпбалалы гаиләләр җир кишәрлекләре алу хокукы булган гражданнар исемлегенә кертү турындагы гаризаларны өлкән балалары 18 яшькә җиткәнче тапшыралар.

Үзгәрешләр, нигездә балалары арасындагы яшь аермасы 18 яшьтән артык булган күпбалалы гаиләләргә генә кагылуын игътибарга алып, бюджет акчаларының өстәмә күләмен фаразларга мөмкинлек бирми.